# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**21 ноябрь 2025 ел** **№1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Уставы белән җыенның йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл хезмәтчәннәреннән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларына (әни, әти), Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнарга бер тапкыр түләүне 2 һәм 3 төркем инвалидларга 250 сум күләмендә билгеләп һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп киметергә:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобилен йөртүченең хезмәтенә түләү, резервуарларга, янгын сүндерү автомобиленә запас частьләр сатып алу);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электр товарлары сатып алу, урам яктырткычларын һәм лампаларын алыштыру, урам яктырткычларын ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре күрсәтү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, үлән чабу, чүп җыюда трактор йөртүченең хезмәтләре өчен түләү)

- - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(чокырларны асфальт белән ремонтлау)?»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 286 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 165 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«хуплап» позициясе өчен гражданнар җыенында 165 катнашучы тавыш бирде; «каршы» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең Сарлы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл хезмәтчәннәреннән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2026 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә ризамы? махсус хәрби операцияләрдә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына (әни, әти), Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнарга бер тапкыр түләүне 2 һәм 3 төркем инвалидларга 250 сум күләмендә билгеләп һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп , үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобилен йөртүченең хезмәтенә түләү, резервуарларга, янгын сүндерү автомобиленә запас частьләр сатып алу);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электр товарлары сатып алу, урам яктырткычларын һәм лампаларын алыштыру, урам яктырткычларын ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре күрсәтү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, үлән чабу, чүп җыюда трактор йөртүченең хезмәтләре өчен түләү)

- - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(чокырларны асфальт белән ремонтлау)?».

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче, И.М.Камалетдинов
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге башлыгы